**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№11193**
**16.11.2023**

Башкарма комитетның «Яр Чаллы шәһәренең «Шәһәр хуҗалыгы дирекциясе» МАУга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә җирләү эше мәсьәләләре буенча махсуслаштырылган хезмәт статусы бирү турында» 2022 елның 24 февралендәге 899 номерлы карары кушымтасына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фонды турында» 2022 елның 14 июлендәге 236-ФЗ номерлы Федераль закон, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы Карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24 пункты нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның «Яр Чаллы шәһәренең «Шәһәр хуҗалыгы дирекциясе» МАУга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә җирләү эше мәсьәләләре буенча махсуслаштырылган хезмәт статусы бирү турында» 2022 елның 24 февралендәге 899 номерлы Карары кушымтасына, 3 пунктның алтынчы абзацын яңа редакциядә бәян итеп, үзгәрешләр кертергә:

«Җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр бәясе, Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фондының тиешле бүлекчәләре, Татарстан Республикасы буенча региональ бүлекчә, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты белән килештереп, Башкарма комитет тарафыннан билгеләнә.».

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитетның шәһәр хуҗалыгы һәм халык яшәешен тәэмин итү идарәсе башлыгы Р.Ф. Вилдановка йөкләргә.

Башкарма комитет Җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы И.С. Зуев